

«Мир цветов» теплица комплексында уналтынчы ел чәчәк vстерvче Наилә Халил кызы Кильдееванын тырыш хезмәте РМ Башлыгынын Рәхмәте, Мордовия Республикасы Дәvләт Жыенынын Мактау грамотасы, Кадошкино районы администрациясе Башлыгынын рәхмәте белән бvләкләнгән. Ул беркайчан да чәчәк vстерv анын очен топ эш торе булыр дип уйламаган.
Наилә Халил кызы Кадошкино районы Большие Поляны авылында туып-vскән. Монда урта мәктәпне тәмамлаган. Аннары укуын Саранск кооператив техникумында техник-технолог белгечлеге буенча дәвам иткән. Ул vзенен хезмәт биографиясен 1989 елда ук, Инсар райпосында сатучы булып башлый. Берничә елдан сон туган авылы кооператив предприятиесенә эшкә кvчә, анда ул 2005 елга кадәр эшли. Ә аннары предприятие бетерелә, ә ул эшсез кала.       - Әлбәттә, Кадошкино бистәсендә теплица комплексы эшли башлаганын белә идем. Розалар теплицада да vстерелә. Һәм, тәвәккәлләп, предприятиенен кадрлар бvлегенә кердем, - дип сойли язма героебыз. Әйтик, 2007 елдан Н.Х.Кильдеева «Мир цветов» нын чәчәк vстерvчесе булып эшли. Ул vзен яна эштә тапканына канәгать. Хәзер vз тормышын ансыз кvз алдына да китерә алмый. Бvген Аква һәм Red Наоми сортлы розаларны vстерә. Үз эшенә бик намуслы карый, участогын игътибар белән кvзәтә; розанын vз вакытында киселvе, vсvе һәм аскы ботакларнын озелvе аркасында әлеге сортларнын унышын ай саен арттыруга ирешә.
- Теплицада һәрберебезнен vз участогы бар һәм мин vземә атап бирелгән мәйданнын ин яхшысы булуын телим. Барысы да мина бәйле икәнен бик яхшы беләм һәм кон саен vз эшемнен нәтижәсен кvрә алам. Бу мине бик соендерә: эшләгән эшемнән ләззәт алам. Безнен эш бер яктан монотонлы, ә икенче яктан - тиз эшләргә кирәк, чонки vсемлек котми. Кайбер мани-пуляцияләрне нәкъ бvген эшләргә кирәк, иртәгә калдырырга ярамый. Әгәр биремнәрне тиешенчә vтәргә кvнекмәгәнсен икән, чәчәк vстерvче булып эшләве кыен булачак.
Табигате буенча Наилә Халил кызы бик мәжбvри һәм жаваплы кеше.
- Ойгә кайтып, барыбер иртәгә vз эшемне ничек планлаштырырга, нәрсәдер килеп

чыкмаса, ничек яхшырак эшләргә кирәклеге турында уйлыйм, - дип фикерләре белән уртаклаша әңгәмәдәшем. - Ә безнен эштә ин моһиме - ана кvнел салу. Коллективта vзара анлашу булсын. Моннан югары кvрсәткечләр дә, дустанә эш атмосферасы да остәлә. Бездә, «Чәчәкләр доньясы»нда, бик яхшы агрономнар эшли, бригадирлар - белемле, компетентлы, vз эшләрен белvчеләр. Һәрвакыт уртак тел табарга, килеп туган проблеманы бергәләп хәл итәргә тырышалар.
Розалар vстерvдә зур тәжрибәсе булган Н.Х.Кильдеевага берничә укучы-чәчәк vстерvче беркетелгән; ул аларны чәчәкләр белән дорес эшләргә ойрәтә. Алга таба яшь чәчәк vстерvчеләр беркетелгән участокларны мостәкыйль карый һәм нәтижәләргә ирешә алачаклар.
- Предприятиедә эшләгән чорда Наилә Халиловнанын бер генә кисәтvе дә юк иде, хезмәттәшләре белән беркайчан да тискәре эмоцияләр кvрсәтмәде, - дип билгеләп vтә «Мир цветов»нын генераль директоры урынбасары - баш агроном С.П.Юдаев. - Без аны яна эшчеләргә vрнәк итеп куябыз, чонки анын профессиональ чәчәк vстерvче буларак ойрәнерлек әйберләре бар. Предприятиедә эшләv дәверендә vзен бары унай яктан гына кvрсәтте. Бик тырыш, ярдәмчел, администрация тарафыннан куелган боерыкларны вакытында һәм сыйфатлы башкара, коллективта аны барысы да хормәт итә.
Н.Х.Кильдееванын яраткан эшеннән тыш, яраткан гаиләсе бар – кайгыртучан ире Фатих, кызы Венера һәм Надия. Әбинен шатлыгына Эмиль, Рамазан һәм София кебек оч сойкемле оныгы vсә. Ул ботен буш вакытын алар белән vткәрә. Наилә Халил кызы яратучан әни һәм әби буларак аларга бәхет һәм унышлар гына тели, аларны авырлыклардан һәм ометсезлекләрдән сакларга тырыша.

**Наилә НАСЫРОВА**